**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

2019 ел 08 октябрь № 290

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем төзү турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль кануны нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү һәм Әтнә районы башкарма хакимияте органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында, Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча 1 нче кушымта нигезендә эшче төркем оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем турында Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Эшче төркем эшчәнлеге турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында даими урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Ф. Каюмов